| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 14.08.2015 г. Казань № 7-3/т

Керә торган тимер юлларда «Менделеевсказот» ҖЧҖе тарафыннан күрсәтелүче транспорт хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында

«Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Керә торган тимер юлларда «Менделеевсказот» ҖЧҖе тарафыннан күрсәтелүче транспорт хезмәтләренә тарифларны әлеге карар кушымтасына нигезләнеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының «Керә торган тимер юлларда Менделеев шәһәренең «Менделеевсказот» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче транспорт хезмәтләренә иң чик максималь тарифлар билгеләү турында» 2011 елның 15 апрелендәге 7-18/т санлы карарының 1 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча Дәүләт комитеты
карарына кушымта
14.08.2015 № 7-3/т

Керә торган тимер юлларда «Менделеевсказот» ҖЧҖе тарафыннан күрсәтелүче транспорт хезмәтләренә тарифлар

I бүлек. Тарифлар

| № п/п | Күрсәтелүче хезмәт төре | Үлчәү берәмлеге | Тариф сумнарда (НДСтан тыш) |
|---|---|---|---|
| 1. | «Менделеевсказот» ҖЧҖе тарафыннан билгеләнеш пункты Тракторная станциясе буенча тимер юлларда йөк ташу, шул исәптән: | | |
| 1.1. | 1 км ераклыкка вагоннарның йөк күтәрүчәнлегеннән файдалануның түбән коэффициентына ия булган йөкләр* | 1 вагон | 229,59 |
| 1.2. | 1 км ераклыкка вагоннарның йөк күтәрүчәнлегеннән норматив файдаланып ташылган йөкләр*, шул исәптән: | | |
| 1.2.1. | айга 3000 тоннага кадәр күләмдә йөк ташыганда | 1 тонна | 9,50 |
| 1.2.2. | айга 3000 тоннадан артык күләмдә йөк ташыганда | 1 тонна | 8,00 |
| 2. | «Менделеевсказот» ҖЧҖе тарафыннан билгеләнеш пункты Менделеевсказот станциясе буенча тимер юлларда 1 км ераклыкка вагоннарның йөк күтәрүчәнлегеннән норматив файдаланып йөк ташу | 1 тонна | 10,50 |

* Россия Федерациясе икътисад Министрлыгының бәяләр буенча Департаменты тарафыннан 1997 елның 10 февралендә килештерелеп, сәнагый тимер юл транспорты тарафыннан башкарылган йөк ташуга, төяү-бушату эшләренә һәм башка хезмәт күрсәтүләргә тарифларны һәм җыемнарны формалаштыру буенча Методик тәкъдимнәргә нигезләнеп, вагоннарның йөк күтәрүчәнлегеннән файдалану коэффициенты предприятие тарафыннан факттагы мәгълүматлар буенча билгеләнә.

II бүлек. Башка шартлар

1. Сәнагый тимер юл транспорты предприятиесе тарафыннан башкарылган, әмма «Тарифлар» дип аталган 1 бүлектә каралмаган эшләргә һәм хезмәтләргә тарифлар Россия Федерациясе транспорт Министрлыгының 2001

елның 20 декабрендәге АН-104-р санлы боерыгы белән расланган сәнагый тимер юл транспорты тарафыннан башкарылган эшләргә һәм башка хезмәт күрсәтүләргә тарифларны һәм җыемнарны формалаштыру буенча Методик тәкъдимнәргә нигезләнеп, яклар килешүе белән билгеләнә.

2. Вагоннарның йөк күтәрүчәнлегеннән норматив файдаланып, йөк ташу һәм төяү-бушату эшләре өчен түләү, йөкнең факттагы авырлыгыннан чыгып, заказчыдан түләтелә.

3. Йөк ташуга түләү алу өчен ераклык, тулы санга кадәр түгәрәкләп, километрларда билгеләнә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дүләт комитеты тариф турында карарлар кабул итүне
оештыру, тикшерүдә тоту һәм тәэмин итү бүлеге